**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында карар**

**20 ноябрь 2025 ел** **№3**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

"«Сез 2026 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утлары челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Симетбаш авылында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Симетбаш авылында Центральная, Нижняя, Нигъматуллина урамнаның урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 103 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 54 граждан кертелде.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 54 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш торак пунктында гражданнар җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. “Сез 2026 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утлары челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Симетбаш авылында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Симетбаш авылында Центральная, Нижняя, Нигъматуллина урамнаның урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

соравы буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Яңа Кишет авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы, Арча районы, Симетбаш авылы, Үзәк урамы, 19а йорты адресы буенча, Арча муниципаль районның (http:// arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф.И.Ахмадуллин
(имза)(имзаның аңлатмасы)